| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.09.2018 № 1414-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 27 апрелендәге 516-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль подсистемасы звеносы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 2018 елның 18 июлендәге 840 номерлы карарын кабул итүгә һәм федераль законнарга туры китерү максатларында Саба районы прокуратурасының 2018 елның 29 августында кабул ителгән 02-08-02-126-2018 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 27 апрелендәге «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы звеносы турында» 516-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль подсистемасы звеносы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 12 пунктның икенче абзацында «кисәтү планнары» сүзләрен «кисәтү буенча гамәлләр планнары» сүзләренә алмаштырырга;

**1.2.** 12 пунктның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

**1.3.** 21 пунктның алтынчы абзацында «эшләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

**1.4.** 23 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

әйләнә-тирәлекнең торышын өйрәнү, гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга китерә торган куркыныч табигать күренешләре һәм техноген процесслар мониторингы, гадәттән тыш хәлләрне фаразлау, шулай ук аларның социаль-икътисади нәтиҗәләрен бәяләү;»;

**1.5.** 23 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкны гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә, шул исәптән экстрен хәбәр итү сигналларын алганда гамәлләргә әзерләү;»;

**1.6.** 23 пунктның унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әйләнә-тирә мохитнең торышын контрольдә тотуны көчәйтү, гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга китерергә сәләтле куркыныч табигать күренешләре һәм техноген процесслар мониторингы, гадәттән тыш хәлләрне фаразлау, шулай ук аларның социаль-икътисадый нәтиҗәләрен бәяләү;»;

**1.7.** 23 пунктның унтугызынчы абзацында «(хезмәттәшлек)» сүзен төшереп калдырырга;

**1.8.** 23 пунктның егерме дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әйләнә-тирә мохитнең торышын өзлексез тикшереп тору, килеп чыккан гадәттән тыш хәлләрнең үсешен мониторинглау һәм фаразлау, шулай ук аларның социаль-икътисадый нәтиҗәләрен бәяләү;»;

**1.9.** 23 пунктта түбәндәге эчтәлекле утыз беренче абзац өстәргә:

халыкка гадәттән тыш хәлләр, аларның параметрлары һәм масштаблары, халыкның һәм территорияләрнең иминлеген тәэмин итү буенча күрелә торган чаралар, гадәттән тыш хәл зонасында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм зыян күрүчеләрне социаль яклау өлкәсендә гражданнарның хокуклары, шул исәптән Россия Федерациясе законнарында каралган түләүләрне алу хокукы, гадәттән тыш хәлләр аркасында югалган документларны торгызу тәртибе турында мәгълүмат бирү.»;

**1.10.** 26 пунктның беренче абзацында «эшләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

**1.11.** 26 пунктның икенче абзацында «эшләр җитәкчеләренең вәкаләтләре» сүзләрен «җитәкчеләрнең вәкаләтләре» сүзләренә алмаштырырга, «эшләр җитәкчеләре килү» сүзләрен «җитәкчеләр килү» сүзләренә, «кисәтү» сүзен «кисәтү гамәлләре» сүзләренә алмаштырырга;

**1.12.** 26 пунктның өченче һәм дүртенче абзацларында «эшләр» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районының
Башкарма комитеты
Җитәкчесе М.Р. Ишниязов